Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

**“19” октябрь 2020 ел** **№ 13**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына яраклаштырып, Арча шәһәре башкарма комитетының «Референдум үткәрүне башлап жибәрү турында» 2020 елның 19 октябрендәге 115 номерлы карары, Арча шәһәр Советының «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» 2020 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карары нигезендә, Арча шәһәре Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча жирле референдумны 2020 елның 6 декабрենә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга: “2021 елда «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?"

1. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам утларын алыштыру һәм урнаштыру, изоляцияләнгән чыбыклар сузу һәм урам утлары баганаларын утырту:

-Арча шәһәре: Юл тыкрыгы; КФҮтән Г. Салихов урамына кадәр квартал; Г. Ахунов урамы; Тимер Юл урамы; М. Галәү урамы; Ватан урамы; Фабрика урамы; Пионер ур., Май тыкрыгы, М. Горький ур., Зур ур., Наратлык ур.;
Астрономнар урамы; Бирәзә тыкрыгы; Г.Салихов урамы; Коммуна урамы; «Казан-Малмыж» автомобиль юлыннан Ф. Әмирхан урамына кадәр квартал; Кәримов урамы; Ямашев урамы.

- Төбәк-Чокырча авылы, Бакча урамы.

- каты көнкүреш һәм коммуналь калдыклар өчен контейнер һәм бункер мәйданчыкларын киртәләп алу һәм аларга керү юллары ясау:

- Арча ш.: Совет мәйданы; Г.Тукай урамы (1 нче квартал); С. Сәйдәшев урамы; Коммуна урамы; Кызыл Бистә урамы; Түбән урам- 1; Түбән урам-2; Түбән урам-3; Тимер юл урамы; Ватан урамы; Фабрика урамы; Көнбатыш тыкрыгы; Кояшлы урамы.

- Иске Айван авылы, Түбән ур., Югары ур.

- материаллар сатып алу һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү:

- Арча шәһәре, Тау өсте ур.;

- Васильева Божа, Кыр ур.;

- Иске Айван авылы, Түбән ур.

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшчәнлеге:

- юлларның нигезен салу һәм вак таш җәю:

- Арча ш.: маршал Жуков ур., (15тән 17нче йортка кадәр); Күпер урамы (31нче йортка керү юлы); Комсомол урамы (78нче йорт); Комсомол урамы (АЗС артында); Кәримов урамыннан Ф. Мансуров урамына кадәр квартал; Ф. Мансуров урамы; Себер тракты ур.; Г. Салихов ур.; Сибгатуллин урамыннан Маяковский урамына кадәр; Сибгатуллин урамыннан Яшьләр урамына кадәр квартал ; Сибгатуллин урамыннан Космонавтлар урамына кадәр 2 нче квартал; Бирәзә урамыннан К. Тинчурин урамына кадәр квартал; Хезмәт урамы, 2а, 2б йорт; Тирәк урамы; Болын урамы; Урманлы тыкрыгы.

- Зур Бирәзә авылы: Арча-Олы Әтнә автомобиль юлыннан зиратка кадәр дамба; Үзәк урамнан Г. Тукай урамына кадәр квартал;

- Күпербаш авылы: Мәктәп урамы; Яр буе урамы; Мичурин урамыннан алып Яр буе урамына кадәр квартал;

- Төбәк-Чокырча авылы: Дан ур., Гагарин ур.;

- Айван авылы: С. Садыйкова урамы, Түбән урамнан Югары урамга кадәр квартал;
- юлларның өслеген вак таш белән каплау:
- Арча шәһәре, Бирәзә ур.;
- Васильев Божа авылы, Магистраль урамы;
- Иске Айван авылы, Түбән ур., Югары ур.

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- 11 данә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:
- Арча ш.: Н. Сафин ур., Шаляпин ур., Зәйнуллин ур., Ш. Күлтәси; Агрономнар урамы; Җиңү урамы; М.Гафури урамы; Маяковский урамы; Яшьләр урамы; Островский урамы; Пионер урамы.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Арча шәһәре Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК"

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27нче йорт; Арча шәһәре, Совет мәйданы, 25 нче йорт; Арча шәһәре, Һ.Такташ ур., 58 нче йорт; Арча шәһәре, Өрәңге ур., 4 нче йорт; Арча шәһәре, Банк урамы, 2а йорт адреслары буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

"Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Арча шәһәр Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы Г. Х. Нигъмәтҗанова

«Совет
города Арск»